**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 маендагы 1708 номерлы карары**

**«Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 19 мартындагы 785 номерлы «“Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү” линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау

проектын әзерләү турында»гы карарына таянып, «Беренчел документларны әзерләү үзәге» акционерлык җәмгыяте гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын расларга (кушымта итеп китерелә).

2. Әлеге карарны, линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (1 нче этап), ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (2 нче этап), планлаштырыла торган сервитутлар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 19 маендагы
1708 номерлы карары белән
расланды

**«Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты**

«Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектын һәм урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы (1, 2 битләр).

II. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турында нигезләмә.

III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап).


IV. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап).

V. Территорияне ызанлау проекты. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (1 нче этап), ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (2 нче этап), планлаштырыла торган сервитут чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән текстлы өлеш.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә

реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (1 нче этап), ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (2 нче этап), планлаштырыла торган сервитут чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган документлар булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

**I.Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектын һәм урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы 1 бит**




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре |
| | линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре |
| 1 | линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы ноктасы |
| | урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре |
| 1 | урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы ноктасы |
| | расланган кызыл линияләр чикләре |

# 2 бит




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре |
| | линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре |
| 1 | линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы ноктасы |
| | урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре |
| 1 | урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы ноктасы |
| | расланган кызыл линияләр чикләре |

## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

### Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектларының, шулай ук урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының атамасы, төп характеристикалары һәм билгеләнеше

Территорияне планлаштыру проекты Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 19 мартындагы 785 номерлы «“Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү” линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары, 2021 елның 16 гыйнварындагы 17/Р номерлы килешү, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә әзерләнде.

Территорияне планлаштыру проекты белән линия объектын план буенча урнаштыру чикләре билгеләнә. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең зурлыгы объектның максатка ярашлылыгыннан, СП 42.13330.2016 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасын исәпкә алып, функциональ билгеләнешеннән чыгып кабул ителә.

СП 42.13330.2016 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасына туры китереп, юлның билгеләнеше нигезендә, шулай ук проектлаштыруга йөкләмә таләпләре буенча юл район әһәмиятендәге магистраль урамнар исемлегенә кертелде.

Территорияне планлаштыру проекты территориясенең мәйданы 38 791 кв.м тәшкил итә.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы мәйданы – 34150 кв.м.

Урамның техник характеристикалары һәм параметрлары СП 42.13330.2016 «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» кагыйдәләр җыелмасы буенча кабул ителде һәм 1 таблицада китерелде.

1 таблица

**Проектлаштырыла торган кишәрлекнең техник характеристикалары**

| № т/б | Атамасы | Үлчәү берәмлеге | 1 нче трасса | 2 нче трасса |
|---|---|---|---|---|

| № т/б | Атамасы | Үлчәү берәмлеге | 1 нче трасса | 2 нче трасса |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Төзелеш төре | | Төзелеш | |
| 2 | Юл категориясе | | Район әһәмиятендәге магистраль урамнар (СП 42.13330.2016 нигезендә) | |
| 3 | Трасса озынлыгы | км | 0,6571 | 0,67469 |
| 4 | Исәпләнгән тизлек | км/сәг | 60 | |
| 5 | Юл катламнары тибы һәм өслекнең төре | | Капиталь | |
| 6 | Хәрәкәт полосалары саны | данә | 2 | |
| 7 | Хәрәкәт полосасы киңлеге | м | 3,50 | |
| 8 | Автомобиль юлының киңлеге | м | 7,0 | |
| 10 | Пландагы кәкренең иң кечкенә радиусы | м | 110 | |
| 11 | Күчәр буйлап иң зур буй авышлык | ‰ | 12 | 5 |
| 12 | Күчәр буйлап иң кечкенә буй авышлык | ‰ | 5 | 5 |
| 13 | Буй профильдә кәкренең иң кечкенә радиусы: | | | |
| | - кабарынкы кәкре | м | 17359 | 552934 |
| | - батынкы кәкре | м | 32235 | 37878 |
| 14 | Юл катламнарына исәпләнгән йөкләнешләр | кН | 115 | |
| 15 | Тротуар киңлеге | м | 2,50-3,75 | |

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләре гамәлдәге җир кишәрлекләрен һәм проектлаштырыла торган объектны ресурслар белән тәэмин итүче, үзгәртеп салына/автомобиль юлыннан чыгарыла торган, шулай ук Казан шәһәр округы Генераль планы белән каралган инженерлык челтәрләрен һәм расланган проект документларын исәпкә алып билгеләнде.

Линия объектларын урнаштыру зоналары гамәлдәге нормативлар нигезендә билгеләнде. Әлеге объектларны башка ысул белән урнаштыру мөмкинлеге юк.

Җирләрне бүлеп бирү күләмнәре проектлаштыруның гамәлдәге нормаларын һәм кагыйдәләрен, төзелешне оештыру буенча карарларны исәпкә алып, җирләрне минималь мәҗбүри алу шартларыннан, технологик максатчанлыктан чыгып кабул ителә.

Объектларны төзү, эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен бүленгән җир полосасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 2 сентябрендәге 717 номерлы «Автомобиль юлларын һәм (яки) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен җирләр бүлеп бирү нормалары турында»гы карары нигезендә кабул ителде.

Эшләр башкару һәм вакытлыча төзелеш хуҗалыгын урнаштыру өчен җирләр бүлеп бирүне төзелеш-монтаж эшләре башланганчы рәсмиләштерү зарур.

Проектта, гамәлдәге челтәрләргә кушып, юл янында тышкы яктырту челтәрләре һәм яңгыр сулары канализациясе төзү каралган.

**Территорияләрендә линия объектын план буенча урнаштыру зонасы билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге җирлекләр, торак пунктлар, шәһәр эчендәге территорияләр исемлеге**

Административ яктан караганда, проектлаштырыла торган юл Казан шәһәренең Киров районында урнашкан һәм Батыршин урамы буйлап, Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр, автомобиль юлының машиналар йөри торган өлешен тәшкил итә.

**Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә линия объекты составына керә торган капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары**

Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрлары билгеләнми.

**Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелеп килүче саклана торган капиталь төзелеш объектларын (бина, төзелмә, корылма, төзелеше тәмамланмаган объектлар), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыру белән бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

Территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә гамәлгә ашырылган яки гамәлгә ашырылачак планлаштырыла торган

капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау буенча чаралар күрү таләп ителми.

**Линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

Планлаштыру проекты чикләрендә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына һәм мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектларның дәүләт исәбенә кертелгән мәдәни мирас объектлары юк; сорала торган җирләр реестрга кертелгән мәдәни мирас объектлары территорияләренең расланган чикләрендә, ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләренең расланган чикләрендә, реестрга кертелгән мәдәни мирас объектларын саклау зоналарының расланган чикләрендә, саклана торган зоналарның расланган чикләрендә, тарих һәм мәдәният өчен аерым әһәмияткә ия тарихи җирлекләр территорияләренең расланган чикләрендә урнашмаган; файдалану (чикләү/хокукларның чикле булуы) режимнары турында белешмәләр юк.

Шуңа бәйле рәвештә мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре схемасы планлаштыру проекты составында китерелми.

Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектларын саклау комитетында (алга таба – Комитет) проект территориясендә ачыкланган мәдәни мирас объектлары яки мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектлар булу яки булмау турында мәгълүмат юк.

Югарыда күрсәтелгәннәрне исәпкә алып, эшләрнең заказчысы, җир эшләре башланганчы, 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль законының 28, 30, 31, 32, 36, 45.1 статьялары нигезендә түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

- җир, төзелеш, хуҗалык эшләре һәм башка эшләр башкарылырга тиешле җир кишәрлегенә 73-ФЗ номерлы федераль законның 45.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә археологик тикшерүләр уздыру юлы белән тарихи-мәдәни экспертиза үткәрүне һәм финанслауны тәэмин итәргә;
- Комитетка җир, төзелеш, хуҗалык эшләре һәм башка эшләр башкарылырга тиешле җир кишәрлегендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларның булуын яки булмавын билгели торган тикшерену

нәтиҗәләрен үз эченә алган документларны, шулай ук күрсәтелгән документларга (яки җир кишәрлегенә) дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен тапшырырга.

Карап тикшерелә торган территориядә ачыкланган археологик мирас объектлары, шулай ук мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектлар табылган очракта, түбәндәгеләрне башкару зарур:

- проект документлары составында ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында яисә кырда башкарыла торган археологик коткару эшләрен уздыру турында бүлекне яки ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү буенча проект яисә уздырыла торган эшләрнең күрсәтелгән мәдәни мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган кырда башкарыла торган археологик коткару эшләрен уздыру планын эшләргә (алга таба – ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының сакланышын тәэмин итү буенча чараларны нигезли торган документлар яисә документлар бүлеге);

- ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү буенча чараларны нигезли торган документлар яки документлар бүлеге буенча дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен алырга һәм аны, килештерү өчен, күрсәтелгән документлар белән бергә Комитетка тапшырырга;

- ачыкланган мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү буенча чараларны нигезли торган килештерелгән документларда күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

## Әйләнә-тирә мохитне саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат

«Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү» объектында, шул исәптән алга таба проект һәм төзелеш-монтаж эшләре кысаларында табигатьне саклау чараларына 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» федераль законның, Россия Федерациясе Җир кодексының, ГОСТ Р 59070-2020 «Әйләнә-тирә мохитне саклау. Бозылган һәм нефть белән пычранган җир кишәрлекләрен рекультивацияләү. Терминнар һәм билгеләмәләр», ГОСТ Р 59060-2020 «Әйләнә-тирә мохитне саклау. Җирләр. Рекультивацияләү максатыннан бозылган җир кишәрлекләрен классификацияләү» һәм

башкаларның гамәлдәге норматив таләпләре нигезендә оператив һәм кисәтү чаралары кертелергә тиеш.

Проект чикләренә җирле, төбәк һәм федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләре керми.

Проектлаштыру чикләрендә түләмә чиреннән үлгән терлек зиратлары һәм биотермик чокырлар теркәлмәгән.

Линия объектын төзегәндә һәм эксплуатацияләгәндә, җир өсте, җир асты һәм грунт суларына йогынты норматив документларда билгеләнгән чикләрдән артмый. Төзелеш эшләре эзлекле рәвештә алып барылганга, бер үк вакытта саклана торган калдыкларның гомуми күләме зур булмаячак. Төзелеш вакытында барлыкка килгән күпчелек калдык төрләренең әйләнә-тирә мохит компонентларына карата тәэсире көчле түгел һәм аларның тискәре йогынтысы территориянең чүпләнүендә генә чагылачак. Шуңа күрә бу чорда төп игътибар калдыкларны вакытында чыгаруга һәм утильләштерүгә юнәлтелә.

Планлаштырыла торган эшләр линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә генә башкарылачак.

## Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48.1 статьясы нигезендә автомобиль юлы аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм җитештерү циклының уникаль объекты булып саналмый, составында куркыныч җитештерүләр һәм аларның участоклары юк. Шулай ук объектта куркыныч матдәләр юк. Димәк, авария нәтиҗәсендә куркыныч матдәләр чыгуны (чыгаруны) бетерү турында карарлар проектлаштыруга йөкләмә белән билгеләнми һәм проектта каралмый.

1997 елның 21 июледәге 116-ФЗ номерлы «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында»гы федераль закон нигезендә автомобиль юллары куркыныч җитештерү объектларына керми.

Төзелеш корылмалары җимерелүгә бәйле аварияләр үсешен кисәтү эксплуатацияләүче оешма көчләре белән даими күзәтү һәм мониторинглау хисабына һәм, авария белән бәйле вазгыять барлыкка килгән очракта, Дәүләт автоинспекциясе органнары белән берлектә эксплуатацияләүче оешма карары нигезендә автомобиль юлы буенча хәрәкәтне туктатып (чикләп), мондый

аварияләрнең башлангыч билгеләрен ачыклау белән ирешелә.


Проектлаштырыла торган корылмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, шул исәптән проектлаштыруның алдагы этапларында да, 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» федераль законы белән билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруны күздә тоту зарур.

Проектлаштырыла торган линия объекты территориясенә иң якын урнашкан янгын сагы бүлекчәсенең адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Яруллин урамы, 1 йорт.

Линия объектының карап тикшерелә торган территориясе мөмкин булган җимерелүләр, химик һәм радиоактив зарарлану, һәлакәтле су басу зоналарына эләкми. Проектлаштырыла торган объект урнашкан районда куркыныч табигый процесслар (җир убылулар, сил һәм кар ташкыннары һ.б.) булмый.

Шул рәвешле, проектлаштыруның алдагы стадияләрендә «Гражданнар оборонасы чаралары, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге» бүлеген эшләү зарурияте юк.


# III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш.
# Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап)




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | территорияне ызанлау проекты чикләре |
| 16:50:270101 | кадастр кварталы чикләре һәм номеры |
| 16:50:270101:3281 | гамәлдәге җир кишәрлеге чикләре һәм кадастр номеры |
| | ясала торган җир кишәрлекләре чикләре |
| н1 | ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы ноктасы номеры |
| | расланган кызыл линияләр чикләре |

# IV. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш.
# Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап)




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | территорияне ызанлау проекты чикләре |
| 16:50:270101 | кадастр кварталы чикләре һәм номеры |
| 16:50:270101:3281 | гамәлдәге җир кишәрлеге чикләре һәм кадастр номеры |
| | ясала торган җир кишәрлекләре чикләре |
| н1 | ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| | расланган кызыл линияләр чикләре |

## V. Территорияне ызанлау проекты. Текстлы өлеш

«Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров районында Галимҗан Баруди урамыннан Зур Крыловка урамына кадәр Батыршин урамын реконструкцияләү» линия объекты территориясен ызанлау проекты территорияне планлаштыру проекты составында эшләнде.

Территорияне ызанлау проекты территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләрен формалаштыру максатыннан әзерләнде.

Җирләрдән рациональ файдалану максатыннан проектта, объектны төзегәндә, реконструкцияләгәндә, аннан файдаланганда, җирләрдән минималь файдалану күздә тотыла.

Карап тикшерелә торган территория 16:50:090531:7, 16:50:090519:3, 16:50:090531:9, 16:50:090519:10, 16:50:090531:8, 16:50:090519:2, 16:50:090519:380, 16:50:090535:10, 16:50:090529:3, 16:50:090506:3, 16:50:090519:20, 16:50:090519:52, 16:50:090506:4, 16:50:090535:359, 16:50:090506:1, 16:50:090518:17, 16:50:090529:1, 16:50:090519:22, 16:50:090506:5, 16:50:090506:26, 16:50:090534:8, 16:50:090532:5, 16:50:090536:35, 16:50:090518:21, 16:50:090530:37, 16:50:090518:15, 16:50:090530:13, 16:50:090519:6, 16:50:090529:2, 16:50:000000:8511, 16:50:000000:26237, 16:50:090530:38, 16:50:090519:383, 16:50:090536:34, 16:50:090530:12, 16:50:090518:16, 16:50:090532:4, 16:50:090530:1, 16:50:090531:6 кадастр номерлы җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан.

2020 елның 31 июлендәге 254-ФЗ номерлы «Инфраструктураны модернизацияләү һәм киңәйтү буенча өстенлекле проектларны гамәлгә ашыру максатыннан аерым мөнәсәбәтләрне җайга салу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты нигезендә инфраструктура объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре мондый инфраструктура объектлары территориясен планлаштыру буенча расланган документлар белән билгеләнә.

Линия объектын план буенча урнаштыру чикләрендә җир кишәрлекләре ясау максатыннан кадастр эшләрен ике этапта башкару таләп ителә. Беренчел һәм ясала торган җир кишәрлекләре турында мәгълүмат 2 таблицада китерелде.

2 таблица

## Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Башлангыч җир кишәрлегенең милек формасы | Беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше | Контур мәйданы, кв.м | Мәйданы, кв.м | Билгеләнә торган рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясалу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1 нче этап** | | | | | | | |
| - | - | - | ЗУ1 (1)<br>ЗУ1 (2)<br>ЗУ1 (3)<br>ЗУ1 (4) | 10 688,73<br>2 896,41<br>1 200,15<br>384,43 | 15 170 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән ясау |
| 16:50:090519:383 | Шәхси | Шәхси торак төзелеше | 16:50:090519:383:ЗУ1 | - | 546 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел кишәрлекне үзгәртелгән чикләрдә саклап бүлү |
| 16:50:000000:26237 | Муниципаль | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү | 16:50:000000:26237:ЗУ1 | - | 2 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел кишәрлекне үзгәртелгән чикләрдә саклап бүлү |
| 16:50:090519:380 | Шәхси | Шәхси торак йорт, территорияне төзекләндерү | 16:50:090519:380:ЗУ1 (1)<br>16:50:090519:380:ЗУ1 (1)<br>16:50:090519:380:ЗУ1 (1) | 723,28<br>416,33<br>0,42 | 1 140 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел кишәрлекне үзгәртелгән чикләрдә саклап бүлү |
| 16:50:090529:3 | Шәхси | Шәхси торак йорт | 16:50:090529:ЗУ1 | | 848 | Шәхси торак төзелеше өчен | Хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге җирләрне яңадан бүлү |
| 16:50:090531:8 | Шәхси | Шәхси торак йорт | 16:50:090531:8:ЗУ1 | | 131 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Беренчел кишәрлекне үзгәртелгән чикләрдә саклап бүлү |
| **2 нче этап** | | | | | | | |

| Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры | Башлангыч җир кишәрлегенең милек формасы | Беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше | Контур мәйданы, кв.м | Мәйданы, кв.м | Билгеләнә торган рөхсәт ителгән файдалану төре | Ясалу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16:50:090532:4<br>16:50:090530:37<br>16:50:090530:38<br>16:50:090530:13<br>16:50:090506:1<br>16:50:090506:26<br>16:50:090506:3<br>16:50:090506:5<br>16:50:090530:12<br>16:50:090529:1<br>16:50:090529:2<br>16:50:090519:2<br>16:50:090519:20<br>16:50:090519:3<br>16:50:090519:52<br>16:50:090535:10<br>16:50:090535:359<br>16:50:090530:1<br>16:50:090531:9<br>16:50:090518:15<br>16:50:090518:16<br>16:50:090518:17<br>16:50:090518:21<br>16:50:090534:8<br>16:50:090506:4<br>16:50:090519:10<br>16:50:090519:22<br>16:50:090519:6<br>16:50:090532:5<br>16:50:090531:6<br>16:50:090536:34<br>16:50:090536:35<br>16:50:090531:7<br>:ЗУ1<br>16:50:090519:383:ЗУ1<br>16:50:000000:26237:ЗУ1<br>16:50:090519:380:ЗУ1<br>16:50:090531:8:ЗУ1 | - | - | ЗУ2 | | 33 305 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милкендәге җирләрне яңадан бүлү |

Гомуми файдаланудагы территорияләргә яки гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлекләре (1 нче этап) турында мәгълүмат 3 таблицада китерелде.

3 таблица

| **Шартлы билге** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Мәҗбүри алу** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 15170 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | - |
| 16:50:090519:383:ЗУ1 | 546 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 16:50:000000:26237:ЗУ1 | 2 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 16:50:090519:380:ЗУ1 | 307 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |
| 16:50:090531:8:ЗУ1 | 131 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә |

Хосусый милектә булган, гомуми файдаланудагы территорияләргә кертеләчәк гамәлдәге җир кишәрлекләре (1 нче этап) турында мәгълүмат 4 таблицада китерелде.

4 таблица

| **Кадастр номеры** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Мәҗбүри алу** |
|---|---|---|---|
| 16:50:090532:4 | 820 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090530:37 | 739 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090530:38 | 113 | Шәхси торак йорт (код 2.1) | Тулысынча |
| 16:50:090530:13* | 516 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090506:1* | 541 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090506:26 | 488 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090506:3 | 684 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория | Тулысынча |

| Кадастр номеры | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу |
|---|---|---|---|
| 16:50:090506:5 | 716 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090530:12* | 253 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090529:2 | 862 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090519:2 | 400 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090519:20 | 500 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория | Тулысынча |
| 16:50:090519:3 | 715 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090519:52 | 814 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090535:10 | 600 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория | Тулысынча |
| 16:50:090535:359 | 265 | Спорт белән шөгыльләнү мәйданчыклары, амбулатория-поликлиника хезмәте күрсәтү, стационар медицина хезмәте күрсәтү, мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү, дәүләт идарәсе | Тулысынча |
| 16:50:090530:1 | 544 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090531:9 | 638 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория | Тулысынча |
| 16:50:090518:15 | 723 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090518:16 | 805 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090518:17 | 772 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |
| 16:50:090531:7 | 451 | Шәхси торак төзелеше | Тулысынча |
| 16:50:090529:1 | 623 | Шәхси торак йорт | Тулысынча |

Искәрмә:

*Мәйданнары турында мәгълүмат Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында декларацияләнгән дип күрсәтелгән җир кишәрлекләренә карата мәҗбүри алына торган өлешнең мәйданы якынча бирелә. Тиешле җир кишәрлекләренең чикләре һәм (яки) мәйданы

алга таба төгәлләштерелгән очракта, мәҗбүри алу мондый җир кишәрлекләренең төгәлләштерелгән мәйданы һәм төгәлләштерелгән чикләре турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне исәпкә алып гамәлгә ашырылырга тиеш.

Муниципаль милектә булган, гомуми файдаланудагы территорияләргә кертеләчәк гамәлдәге җир кишәрлекләре (1 нче этап) турында мәгълүмат 5 таблицада китерелде.

5 таблица

| **Кадастр номеры** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** |
|---|---|---|
| 16:50:090534:8* | 706 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090506:4* | 723 | Хәрабәләр |
| 16:50:090519:10* | 196 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090519:22 | 630 | Ташландык урын |
| 16:50:090519:6* | 764 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090532:5 | 466 | Автомобиль юлы |
| 16:50:090531:6* | 752,3 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090536:34 | 501 | Автомобиль юлы |
| 16:50:090536:35 | 26 | Автомобиль юлы |
| 16:50:090518:21 | 158 | Янәшәдәге территория өчен |

Искәрмә:

*Мәйданнары турында мәгълүмат Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында декларацияләнгән дип күрсәтелгән җир кишәрлекләренә карата резервлана торган өлешнең мәйданы якынча бирелә. Тиешле җир кишәрлекләренең чикләре һәм (яки) мәйданы алга таба төгәлләштерелгән очракта, резервлау мондый җир кишәрлекләренең төгәлләштерелгән мәйданы һәм төгәлләштерелгән чикләре турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне исәпкә алып гамәлгә ашырылырга тиеш.

Җир кишәрлегендә хосусый милектәге капиталь төзелеш объекты урнашкан очракта, аны мәҗбүри алу таләп ителә.

Гомуми файдаланудагы территорияләргә яки гомуми файдаланудагы милеккә кертеләчәк ясала торган җир кишәрлеге (2 нче этап) турында мәгълүмат 6 таблицада китерелде.

6 таблица

| **Шартлы билге** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** |
|---|---|---|

| Шартлы билге | Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре |
|---|---|---|
| ЗУ2 | 33305 | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) |

Линия объектларын төзү һәм реконструкцияләү чорына (шул исәптән җәяү һәм транспортта үтеп йөрүне тәэмин итү, шулай ук төзелеш һәм башка материалларны саклау, вакытлыча яки ярдәмче корылмалар урнаштыру өчен) линия объектларын сервитут, төзелешнең ачык сервитуты шартларында урнаштырырга мөмкин булган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләреннән, җир кишәрлекләре өлешләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре 7 таблицада китерелде

7 таблица

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Ачык сервитут мәйданы, кв.м | Рөхсәт ителгән файдалану төре |
|---|---|---|
| 16:50:090532:4 | 820 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090530:37 | 739 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090530:38 | 113 | Шәхси торак йорт (код 2.1) |
| 16:50:090530:13 | 516 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090506:1 | 612 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090506:26 | 487 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090506:3 | 684 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория |
| 16:50:090506:5 | 716 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090530:12 | 253 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090529:1 | 623 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090529:2 | 862 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090529:3 | 542 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090519:2 | 400 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090519:20 | 500 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория |
| 16:50:090519:3 | 715 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090519:380 | 307 | Шәхси торак йорт, территорияне төзекләндерү |
| 16:50:090519:52 | 814 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090535:10 | 600 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория |
| 16:50:090535:359 | 265 | Спорт белән шөгыльләнү |

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Ачык сервитут мәйданы, кв.м | Рөхсәт ителгән файдалану төре |
|---|---|---|
| | | мәйданчыклары, амбулатория-поликлиника хезмәте күрсәтү, стационар медицина хезмәте күрсәтү, мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү, дәүләт идарәсе |
| 16:50:090530:1 | 543 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090531:8 | 131 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090531:9 | 638 | Шәхси торак йорт һәм аның янәшәсендәге территория |
| 16:50:090518:15 | 723 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090518:16 | 803 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090518:17 | 772 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090518:21 | 158 | Янәшәдәге территория өчен |
| 16:50:090534:8 | 706 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090506:4 | 791,5 | Хәрабәләр |
| 16:50:090519:10 | 196 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090519:22 | 630 | Ташландык урын |
| 16:50:090519:6 | 659 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090532:5 | 466 | Автомобиль юлы |
| 16:50:000000:8511 | 74640 | Автомобиль юлы |
| 16:50:090531:6 | 735 | Шәхси торак йорт |
| 16:50:090536:34 | 501 | Автомобиль юлы |
| 16:50:090536:35 | 26 | Автомобиль юлы |
| 16:50:090519:383 | 546 | Шәхси торак төзелеше |
| 16:50:090531:7 | 451 | Шәхси торак төзелеше |
| 16:50:000000:26237 | 2 | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү |

Эксплуатацияләү чорына планлаштырыла торган сервитутлар турында мәгълүмат 8 таблицада китерелде.

8 таблица

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Ачык сервитут мәйданы, кв.м | Рөхсәт ителгән файдалану төрләре |
|---|---|---|
| 16:50:000000:8511 | 836 | Автомобиль юлы |